# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2021 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 19 ноябрендә 11.00 сәгатьтә үткәрелгән «2021 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Сарысаз-Тәкермән авылында I төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе тозелде:

1) Сарысаз-Тәкермән торак пункты зиаратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2)Сарысаз-Тәкермән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

3)Сарысаз-Тәкермән торак пунктында Беларусь-МТЗ 82 махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4)СарысазТәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;

5)Сарысаз-Тәкермән пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу;

6)Сарысаз-Тәкермән торак пункты өчен генератор сатып алу;

7)Янгын ранцы (1 данә), янгын краннары ( 2 данә) сатып алу.

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 150 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 108 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 108 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл жирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар жыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Сарысаз-Тәкермән авылында 1 төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Сарысаз-Тәкермән торак пункты зиаратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2)Сарысаз-Тәкермән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

3)Сарысаз-Тәкермән торак пунктында Беларусь-МТЗ 82 махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4)СарысазТәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;

5)Сарысаз-Тәкермән пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу;

6)Сарысаз-Тәкермән торак пункты өчен генератор сатып алу;

7)Янгын ранцы (1 данә), янгын краннары ( 2 данә) сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче

Р.Ә.Исламова